## СУДА ЗЫЯН КҮРҮЧЕЛӘРГӘ ЯРДӘМ КҮРСӘТҮ



Әгәр батучы су өслегендә мөстәкыйль тора ала икән, аңа бөят ташлагыз

Батучы янына сак кына йөзәргә кирәк. Иң яхшысы аны култык астыннан тотып, йөзе өскә караган килеш ярга алып чыгарга





Зыян күргән кешене корсагы белән тезегезгә салыгыз, су чыксын, авыз куышлыгын чит әйберләрдән чистартыгыз

Яшәү билгеләре булмаганда, кичекмәстән йөрәк-үпкә реанимациясе ясарга кирәк



**2021 елның 1 июненнән казанлылар һәм шәһәр кунаклары өчен «Локомотив», «Түбән Заречье», «Комсомольское Күле», «Тирән Күл», «Аккош Күле» пляжлары ачык. Шулай ук Изумрудное һәм Кече Аккош күлләрендә, Җиңү Паркында су янында ял итү урыннары оештырылган**

**ИСТӘ ТОТЫГЫЗ !**


**Суда кеше үлеменең төп сәбәпләре булып түбәндәгеләр тора:**

- исерек хәлдә коену (50% очрак)
- баш һәм умырткалык җәрәхәтләре (30% очрак);
- Көзән, баш мие спазмалары, температура төшкәндә сулыш тукталышы (20% очрак)

**Бердәм коткару хезмәте телефоны** 112

Татарстан Республикасы ГО һәм ГТХ буенча укыту-методик үзәгенең ГО һәм ГТХ белгечләре һәм вазыйфаи затларны әзерләү бүлеге

# СУДА КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК КАГЫЙДӘЛӘРЕ



**БЕЛЕШМӘЛЕК**


Казан ш.

## РӨХСӘТ ИТЕЛӘ!




Билгеләнгән урыннарда гына коенырга була!

Тикшерелгән, тигез төпле тирән урыннарда гына чумыгыз!





Чикләү билгеләре эчендә коену өчен билгеләнгән урыннарда коеныгыз!

Судан куркынычсыз ераклыкта уйнагыз!



## КУРКЫНЫЧ !

Кабарынкы йөзү җайланмаларында ерак йөзмәгез!





Артык өшемәгез һәм кызмагыз, ашаганнан соң 1,5 - 2 сәгать тәнәфес ясагыз!

Су коенуны тыя торган билгеләр урыннарында йөзмәгез!






Көчле агымга каршы йөзәргә тырышмагыз, агым буенча акрынлап ярга таба якыная йөзегез!

## ТЫЕЛА !



Шторм вакытында коенмагыз!

Йөзү өчен кулдан эшләнгән җайланмаларны кулланмагыз!





Көймәләрдә, катерларда, һәм гидроциклларда кешеләр коену урыннарында йөрмәгез!

Көймәләр һәм катерлар бортларыннан сикермәгез!

